РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» ноябрь 2023 ел г. Альметьевск № 7377

Әлмәт шәһәре территориясендә күмү
урыннарын карап тоту өлешендә
җирләү мәсьәләләре буенча
махсуслаштырылган оешманы
билгеләү турында

«Күмү һәм җирләү эше турында»1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районына тапшыру турында Әлмәт шәһәр Советының тәкъдимнәрен кабул итү хакында» 2023елның 29 мартындагы 208 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕИТ КАРАР БИРӘ :

1. «Үсеш департаменты» муниципаль автоном учреждениесен (алга таба – учреждение) Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган оешма итеп билгеләргә (килешү буенча).
2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган оешманы билгеләү турында» 2020 елның 19 февралендәге 211 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

Зак. № 305-2000